**Балаларның сөйләмен үстерүдә әвәләүнең әһәмияте**

**(ата-аналар өчен консультация)**



**Әзерләде:**

**Галлямова Г.Д.**

Балаларга күпкырлы тәрбия һәм үсеш бирүдә әвәләү шөгыленең дә урыны зур. Балаларның баш миен, псхикасын өйрәнүче галимнәр кул һәм бармак хәрәкәтләренең зур стимуллаштыру әһмиятенә ия булуын билгелиләр. Аларның сөйләм үсеше турыдан-туры бармакларның нәфис, нечкә хәрәкәтләре формалашу дәрәҗәсенә бәйле. Бармаклар авыр хәрәкәтләнсә сөйләм үсеше дә тоткарлана. Балалардагы искиткеч кызыксынучанлык: һәр нәрсәне тотып, кабып, танып белү теләге бездән-өлкәннәрдән зур игътибар сорый. Ә аларның кечкенә куллары, кечкенә бармаклары һәрвакыт нинди дә булса шөгыль эзләүдә.

Кечкенәләр төркемендә күбрәк сенсорик тәрбиягә игътибар бирелә. Әвәләгәндә исә безнең бармакларыбыз, кулларыбыз хәрәкәтләнә. Нәкъ менә бармакларны күбрәк хәрәкәтләндерү акыл сәләтен үстерүгә ярдәм итә. Шушы максаттан мин үз практикамда күбрәк әвәләү шөгыленә игътибар бирергә тырышам.

Әвәләү өчен пластилиннан, балчыктан, камырдан, әвәли торган массалардан файдаланырга була. Мин үзем күбрәк камырны кулай күрәм.

Камыр - экологик чиста һәм аллергия бирми торган материал. Аны кулга алу белән бик тә рәхәтләнеп әвәлисе дә әвәлисе килә. Камырны ясау да бер дә катлаулы түгел.

Аны кухня өстәлендә теләгән вакытта ясарга була. Камыр куллардан бик җиңел юыла. Технологияне дөрес кулланы ясаганда, камыр кулларга ябышмый һәм бик тә пластик, аннан төрлечә әвәләргә була.

Камыр ясау өчен 2 стакан он, 1 стакан тоз (“Экстра” тозы) һәм ¾ стакан салкын су алына (тоз камыр озак саклансын өчен, бөҗәклардән саклау өчен кирәк). Камырны целлофан пакетта холодильникта озак вакыт сакларга була. Камырдан ясалган әйберләлне батарея өстендә, бүлмә

температурасында, кояшта һәм духовкада киптерергә була. Кипкән камырны матур буяулар белән буяп, без балаларыбызны тагын да куандыра алабыз. Буяу өчен кишер, чөгендер согыннан, зеленкадан, гуашь һәм акрил буяулардан файдаланырга була. Камырга буяуларны әвәләгәнче өлешләп кушарга һәм төсле камырдан әвәләргә дә мөмкин. Тозлы камырдан әвәләү буенча китапларны кибетләрдән алырга яки интернет аша да бик рәхәтләнеп өйрәнергә була.

Минем үземнең кечкенәләр төркемендә әвәләүнең иң гади ысуллары кулланам. ФГОС программасы буенча, безнең максатта:

1) балаларны әвәләргә кызыксындыру, әвәләү материала белән чиста-пөхтә эш итәргә өйрәтү;
2) зур кисәктән кечкенә кисәкне аерып алу алымын өйрәтү, түгәрәк (шар, туп, колобок, алма h\б) һәм озынча формалар (таяклар, колбаски h\б) әүәләү, озынча формаларны түгәрәпләп башларын беркетү (тәгәрмәч, колечко, бараночка);
3) түгәрәк формаларны учлар белән изү (печенье, пряник, лепешки) алымнарын өйрәтү;
4) әвәләнгән ике форманы берләштерү, алымын үстерү (таяк һәм шариктан шалтыравык, гомбә, түгәрәкләрдән неваляшка h\б).